Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Эсләк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**12.11.2025** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 12 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта “Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Эсләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (I төркем инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм ителгән затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекчеләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан ( бергә яшәүче ата-аналары, ирләре яки хатыннары, балигъ булган балаларыннан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

1. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җиһазлар сатып алу һәм башка чыгымнар);

2.Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен, колонкаларны ремонтлау һәм Иске Эсләк торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

3. Торак пунктның төзекләндерү: газон һәм чүп үләннәрен чабу, кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган авария хәлендәге һәм корыган агачларны кисү һәм чыгару; юлларны кардан чистарту һәм башка чыгымнар: трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьлар сатып алу; 1данә триммер, 1данә электропычкы сатып алу, ял паркын төзекләндерү һәм башка чыгымнар.

4. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу һәм янгын сүндерү машинасын тоту өчен башка чыгымнар).

башкаруга юнәлтүгә, кулланугa ризамы?" дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ»

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 200 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 105 кеше, бу 52% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 105 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Эсләк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Эсләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән ( I төркем инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм ителгән затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекелеләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан ( бергә яшәүче ата-аналары, ирләре яки хатыннары, балигъ булган балаларыннан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җиһазлар сатып алу һәм башка чыгымнар);

2.Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен, колонкаларны ремонтлау һәм Иске Эслэк торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

3. Торак пунктның төзекләндерү: газон һәм чүп үләннәрен чабу, кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган авария хәлендәге һәм корыган агачларны кисү һәм чыгару; юлларны кардан чистарту һәм башка чыгымнар: трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьлар сатып алу, 1данә триммер, 1данә электропычкы, халыкның ял итү урынын төзекләндерү өчен төзү материаллары сатып алу һәм башка чыгымнар.

4. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу һәм янгын сүндерү машинасын тоту өчен башка чыгымнар).

5) Торак пукт чигендәге җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонлау, карап тоту һәм Иске Эслэк авылы юлларына салу өчен вак таш сатып алу, салдыру һәм башка чыгымнар.

6) Зират коймасын ремонтлау, өлешчә әйләндереп алу, төзекләндерү, эшләгән өчен түләү һәм башка чыгымнар.

4.Карарны Иске Эслэк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (https://agryz.tatarstan.ru), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru).

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы Г.г.Әхмәтова